## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Наратлы-Кичү торак пунктында
2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**24 ноябрь 2023ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 №131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы Кичү авыл җирлеге Наратлы-Кичү торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы-Кичү авыл җирлеге Наратлы-Кичү торак пункты территориясендә үзара салымны 2024 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, 1и 2 группа инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән тыш.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Наратлы- Кичү торак пунктындагы Карл Маркс, Галиәскәр Камал, Габдулла Тукай, Үзәк урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау(вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Наратлы-Кичү авыл җирлеген мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында http://menzelinsk/tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге башлыгы ____________ Вәлиев И.М.
(имза)